**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 02.08.2024 | Казан ш. | **БОЕРЫК** № 846-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының "Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлеген рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен раслау турында" 2017 елның 6 декабрендәге 1465-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакынла

Министрлыкның норматив хокукый актын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 22 сентябрендәге 895 номерлы карарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 6 декабрендәге 1465-п номерлы боерыгына (2018 елның 26 февралендәге 164-п номерлы боерык нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 21 августындагы 603 номерлы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 22 сентябрендәге 895 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «министр урынбасары Ф.Ф.Шакировка» сүзләрен «министрның беренче урынбасары И.И.Гобәйдуллинга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән

бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибендә:

3 пунктта «министр урынбасары – Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә баш дәүләт инспекторы» сүзләрен «министрның беренче урынбасары –Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә баш дәүләт инспекторы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков